| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Старосляковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Иске Эсләк авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.11.2018 Иске Эсләк авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Иске Эсләк авылында гражданнарның үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иске Эсләк авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.2018 елның 20 ноябренә Иске Эсләк авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 11.00 сәгатькә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенында карала торган сорауны расларга: «I группа инвалидлар, торып укучы студентлардан, Иске Эсләк авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 400 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау.
2. Су белән тәэмин итүне оештыру.
3. Җирлек территориясен төзекләндерү.
4. Иске Эсләк авылы урамнарын кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3.Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрүне йөкләргә.

4.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыгу көненнән үз көченә керә.

И.Н. ГАФАРОВ